ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕСУБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ СУБАШ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«10» ноябрь 2025 ел №30

**«Чүпне, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм төрле эшләнмәләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 20.12.2018 елгы 17 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге башкарма комитеты карарына (2023 елның 14 марттагы 8 номерлы редакциядә) үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 03.02.2025 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Чүпне, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм төрле эшләнмәләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 20.12.2018 елгы 17 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге башкарма комитеты карарына (2023 елның 14 марттагые 8 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «1.1. Торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан хосусый йорт биләмәләрендә азык әзерләү өчен ачык ут куллану, шулай ук чүп-чар, үлән, яфрак һәм башка калдыкларны, махсус билгеләнгән һәм җиһазландырылган урыннан тыш материалларны яисә эшләнмәләрне яндыру тыела.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Югары Субаш авыл җирлеге башлыгы А. А. Хөснетдинов